# МИН СИНЕ ШУНДЫЙ САГЫНДЫМ

*ЛУИЗА БАТЫРКАЕВА музыкасы*
*ФИРАЯ ЗЫЯТДИНОВА сүзләре*

Мин сине шундый сагындым,
Сизәсең микән шуны?
Ак бураннар урап алса,
Табарсың микән юлны?

*Кушымта:*
Син дә шулай сагына калсаң,
Карама җилләренә...
Җыр булып килеп керерсең
Наз тулы йөрәгемә.

Мин сине шундый сагындым.
Күзләрем шуңа моңлы.
Айны болытлар капласа,
Табарсың микән юлны?

*Кушымта:*
Син дә шулай сагына калсаң,
Карама җилләренә...
Җыр булып килеп керерсең
Наз тулы йөрәгемә.